# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об обеспечении доступа к информации о деятельности государственных органов Республики Татарстан и органов местного самоуправления в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
15 декабря 2022 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 16 января 2015 года № 3-ЗРТ «Об обеспечении доступа к информации о деятельности государственных органов Республики Татарстан и органов местного самоуправления в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2015, № 1 – 2, № 10 (I часть) следующие изменения:

1) дополнить статьей $1^1$ следующего содержания:
«Статья $1^1$. **Понятия, используемые в настоящем Законе**

Понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в значениях, установленных Федеральным законом.»;

2) часть 1 статьи 4 изложить в следующей редакции:
«1. Доступ к информации о деятельности государственных органов и органов местного самоуправления обеспечивается соответствующими структурными подразделениями или уполномоченными должностными лицами указанных органов и организациями, подведомственными государственным органам, органам местного самоуправления (далее – подведомственные организации).»;

3) статью 5 изложить в следующей редакции:
«Статья 5. **Организация доступа к информации о деятельности государственных органов, органов местного самоуправления, размещаемой в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет»**

1. Государственные органы, органы местного самоуправления для размещения информации о своей деятельности используют информационно-телекоммуникационную сеть «Интернет», в которой создают официальные сайты с указанием адресов электронной почты, которые созданы в соответствии с требованиями, определяемыми Правительством Российской Федерации, и по которым пользователем информацией может быть направлен запрос и получена запрашиваемая информация. Подведомственные организации по решению государственных органов, органов местного самоуправления, в ведении которых находятся такие организации, создают официальные сайты, за исключением случаев, предусмотренных федеральными законами. В случае, если орган местного самоуправления и подведомственная ему организация не имеют возможности создать официальные сайты, информация об их деятельности может размещаться на официальном сайте (портале) Республики Татарстан. Информация о деятельности органов местного самоуправления поселений, входящих в муниципальный район, и подведомственных органам местного самоуправления поселений организаций может размещаться на официальном сайте этого муниципального района. В соответствии с федеральными законами может быть предусмотрено создание единого портала, на котором размещаются несколько официальных сайтов государственных органов, органов местного самоуправления и (или) подведомственных организаций.

2. Государственные органы, органы местного самоуправления и подведомственные организации создают официальные страницы для размещения информации о своей деятельности в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет». Подведомственные организации с учетом особенностей сферы их деятельности по согласованию с государственными органами и органами местного самоуправления, в ведении которых такие организации находятся, могут не создавать официальные страницы для размещения информации о своей деятельности в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет». Информация об официальных страницах с указателями данных страниц в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» размещается на официальном сайте соответствующих государственного органа, органа местного самоуправления или подведомственной организации.

3. Государственные органы, органы местного самоуправления и подведомственные организации осуществляют размещение информации на своих официальных страницах, получают доступ к информации, размещаемой на официальных страницах, и осуществляют взаимодействие с пользователями информацией на официальных страницах с использованием инфраструктуры, обеспечивающей информационно-технологическое взаимодействие информационных систем, используемых для предоставления государственных и муниципальных услуг и исполнения государственных и муниципальных функций в электронной форме, предусмотренной Федеральным законом от 27 июля 2010 года № 210-ФЗ «Об организации предоставления государственных и муниципальных услуг», в порядке, установленном Правительством Российской Федерации.

4. Официальные сайты и официальные страницы взаимодействуют с федеральной государственной информационной системой «Единый портал государственных и муниципальных услуг (функций)» в порядке и в соответствии с требованиями, которые утверждаются Правительством Российской Федерации.

5. Информация на официальных сайтах государственных органов, органов местного самоуправления и подведомственных организаций в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» размещается на государственных языках Республики Татарстан.

6. Требования к технологическим, программным и лингвистическим средствам обеспечения пользования официальными сайтами государственных органов и подведомственных им организаций, а также органов местного самоуправления и подведомственных им организаций устанавливаются в пределах своих полномочий указанными органами.

7. Обеспечение условий доступности для инвалидов по зрению официальных сайтов государственных органов, органов местного самоуправления и подведомственных организаций осуществляется в порядке, установленном федеральным законодательством.»;

4) в статье 6:

а) в наименовании слова «в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» заменить словами «на официальных сайтах»;

б) в части 1 слова «в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» заменить словами «на официальных сайтах»;

в) часть 5 после слова «утверждаются» дополнить словами «в порядке, определяемом»;

г) дополнить частью 7 следующего содержания:

«7. Перечень информации о деятельности подведомственных организаций, размещаемой на их официальных сайтах, утверждается государственными органами, органами местного самоуправления, в ведении которых такие организации находятся.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ / ГОМУМИ БҮЛЕК — АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казань, Кремль
20 декабря 2022 года
№ 91-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 1 – 2, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ статья өстәргә:
«$1^1$ статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.»;

2) 4 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге күрсәтелгән органнарның тиешле структур бүлекчәләре яисә вәкаләтле вазыйфаи затлары һәм дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар (алга таба – ведомство буйсынуындагы оешмалар) тарафыннан тәэмин ителә.»;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштырыла торган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру**

1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланалар, анда, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә булдырылган, мәгълүматтан файдаланучы тарафыннан гариза юллану һәм соралган мәгълүмат алыну мөмкинлеге булган электрон почта адресларын күрсәтеп, рәсми сайтлар булдыралар. Ведомство буйсынуындагы оешмалар үз карамагында мондый оешмалар булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары карары буенча, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми сайтлар булдыралар. Җирле үзидарә органының һәм аның буйсынуындагы оешманың рәсми сайтлар булдыру мөмкинлеге булмаган очракта, аларның эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы рәсми сайтында (порталында) урнаштырылырга мөмкин. Муниципаль районга керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар эшчәнлеге турында мәгълүмат шул муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин. Федераль законнар нигезендә дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм (яисә) ведомство буйсынуындагы оешмаларның берничә рәсми сайтлары урнаштырыла торган бердәм портал булдыру каралырга мөмкин.

2. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми битләр булдыралар. Ведомство буйсынуындагы оешмалар, аларның эшчәнлеге өлкәсе үзенчәлекләрен исәпкә алып, үз карамагында мондый оешмалар булган дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән килештереп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми битләр булдырмаска мөмкин. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми битләр турында мәгълүмат әлеге битләрнең күрсәткечләре белән тиешле дәүләт органының, җирле үзидарә органының яисә ведомство буйсынуындагы оешманың рәсми сайтында урнаштырыла.

3. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үзләренең рәсми битләрендә мәгълүмат урнаштыруны гамәлгә ашыралар, рәсми битләрдә урнаштырыла торган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген алалар һәм мәгълүматтан файдаланучылар белән хезмәттәшлекне, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда каралган электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм дәүләт функцияләрен һәм муниципаль функцияләрне башкару өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурадан файдаланып, рәсми битләрдә гамәлгә ашыралар.

4. Рәсми сайтлар һәм рәсми битләр «Дәүләт хезмәтләре (функцияләре) һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы белән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган тәртиптә һәм таләпләр нигезендә хезмәттәшлек итәләр.

5. Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

6. Дәүләт органнарының һәм аларның буйсынуындагы оешмаларның, шулай ук җирле үзидарә органнарының һәм аларның буйсынуындагы оешмаларның рәсми сайтларыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программага караган һәм лингвистик чараларына таләпләр күрсәтелгән органнар тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә билгеләнә.

7. Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларның рәсми сайтларыннан күрү буенча инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

4) 6 статьяда:

а) исемендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен «Рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 өлештә «тарафыннан» сүзеннән соң «билгеләнә торган тәртиптә» сүзләрен өстәргә;

г) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Ведомство буйсынуындагы оешмаларның эшчәнлеге турында аларның рәсми сайтларында урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеге үз карамагында мондый оешмалар булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 20 декабрь
№ 91-ТРЗ